**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О Совете по вопросам кадровой политики при Президенте Республики Татарстан

В целях совершенствования работы по реформированию и развитию государственной гражданской службы Республики Татарстан и муниципальной службы в Республике Татарстан, в соответствии с частью 3 статьи 42 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан», а также в целях формирования и эффективного использования резерва управленческих кадров Республики Татарстан **постановляю**:

1. Образовать Совет по вопросам кадровой политики при Президенте Республики Татарстан.

2. Утвердить Положение о Совете по вопросам кадровой политики при Президенте Республики Татарстан (приложение № 1) и его состав (приложение № 2).

3. Упразднить:
Комиссию по формированию и подготовке резерва управленческих кадров в Республике Татарстан;
Комиссию по вопросам развития государственной гражданской службы Республики Татарстан и муниципальной службы в Республике Татарстан.

4. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 22 ноября 2008 года № УП-599 «О государственном заказе на профессиональную переподготовку, повышение квалификации и стажировку государственных гражданских служащих Республики Татарстан» (с изменением, внесенным Указом Президента Республики Татарстан от 20 марта 2013 года № УП-240) следующие изменения:

а) в абзаце первом пункта 3 и абзаце втором пункта 4 слова «Департамент по делам государственных служащих при Президенте Республики Татарстан» в соответствующем падеже заменить словами «Департамент государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан» в соответствующем падеже;

б) в Положении о государственном заказе на профессиональную переподготовку, повышение квалификации и стажировку государственных гражданских служащих Республики Татарстан:

в пункте 5, абзацах первом и втором пункта 6, пункте 8, абзацах первом и втором пункта 9, пункте 12, абзаце первом пункта 13, пунктах 15 и 16 слова «Департамент по делам государственных служащих при Президенте Республики Татарстан» в соответствующем падеже заменить словами «Департамент государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан» в соответствующем падеже;

в абзаце втором пункта 6 слова «Комиссии по вопросам развития государственной гражданской службы Республики Татарстан и муниципальной службы в Республике Татарстан» заменить словами «Совета по вопросам кадровой политики при Президенте Республики Татарстан».

5. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 25 февраля 2009 года № УП-97 «О порядке формирования резерва управленческих кадров Республики Татарстан» следующие изменения:

а) в пункте 4 и абзаце втором пункта 5 слова «Департамент по делам государственных служащих при Президенте Республики Татарстан» в соответствующем падеже заменить словами «Департамент государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан» в соответствующем падеже;

б) в Положении о порядке формирования резерва управленческих кадров Республики Татарстан:

в пункте 3 слова «формируется Комиссией по формированию и подготовке резерва управленческих кадров в Республике Татарстан (далее – Комиссия)» заменить словами «формируется Советом по вопросам кадровой политики при Президенте Республики Татарстан (далее – Совет)»;

в абзаце третьем пункта 6, пунктах 13-23, 26 и приложении № 2 к анкете претендента для включения в резерв управленческих кадров Республики Татарстан слово «Комиссия» в соответствующем падеже заменить словом «Совет» в соответствующем падеже;

в абзаце первом пункта 11, абзаце первом пункта 12, пунктах 14, 22, 23 и 25 слова «Департамент по делам государственных служащих при Президенте Республики Татарстан» в соответствующем падеже заменить словами «Департамент государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан» в соответствующем падеже.

6. Признать утратившими силу указы Президента Республики Татарстан согласно приложению № 3.

7. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
12 июня 2014 года
№ УП-569

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «12» июня 2014 года

№ УП-569

**Положение**
**о Совете по вопросам кадровой политики**
**при Президенте Республики Татарстан**

1. Совет по вопросам кадровой политики при Президенте Республики Татарстан (далее – Совет) образуется в целях эффективного использования кадрового потенциала Республики Татарстан, содействия развитию системы государственной гражданской службы Республики Татарстан и муниципальной службы в Республике Татарстан (далее – государственная и муниципальная служба), а также реализации единой кадровой политики в Республике Татарстан.

2. Совет в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

3. Положение о Совете и его состав утверждаются Президентом Республики Татарстан.

4. Основными функциями Совета являются:

а) подготовка предложений Президенту Республики Татарстан по совершенствованию кадровой политики Республики Татарстан, организации и прохождения государственной и муниципальной службы, системы управления кадрами в Республике Татарстан;

б) подготовка предложений Президенту Республики Татарстан по совершенствованию законодательства Российской Федерации и Республики Татарстан о государственной и муниципальной службе;

в) обеспечение формирования резерва управленческих кадров Республики Татарстан и его эффективного использования;

г) мониторинг реализации республиканских программ развития государственной и муниципальной службы;

д) анализ эффективности организации профессиональной переподготовки, повышения квалификации государственных гражданских и муниципальных служащих в Республике Татарстан;

е) подготовка предложений по замещению должностей, назначение на

которые и освобождение от которых осуществляются Президентом Республики Татарстан или Кабинетом Министров Республики Татарстан;

ж) подготовка предложений Президенту Республики Татарстан о согласовании кандидатур, представленных для назначения на должности руководителей территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, осуществляющих свои полномочия на территории Республики Татарстан, в случаях, предусмотренных федеральным законодательством, договорами и соглашениями;

з) осуществление мониторинга реализации кадровой политики в органах исполнительной власти Республики Татарстан, а также в подведомственных им учреждениях, информирование Президента Республики Татарстан о положении дел в этой области;

и) подготовка предложений Президенту Республики Татарстан и осуществление организационных мероприятий по проведению оценки профессиональной деятельности лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан, государственных гражданских служащих Республики Татарстан, замещающих должности государственной службы категории «руководители» высшей группы должностей;

к) подготовка предложений об организации и проведении республиканских семинаров, совещаний, конференций по наиболее актуальным проблемам развития государственной и муниципальной службы, развития персонала и управления им, по вопросам обобщения и распространения современного отечественного и зарубежного передового опыта подготовки специалистов в сферах государственного и муниципального управления;

л) рассмотрение по поручению Президента Республики Татарстан иных вопросов, относящихся к компетенции Совета.

5. Совет для реализации возложенных на него основных функций имеет право:

а) запрашивать и получать в установленном порядке необходимую информацию и материалы от государственных органов, органов местного самоуправления, общественных объединений, научных и других организаций;

б) создавать по вопросам, относящимся к компетенции Совета, постоянные и временные рабочие и экспертные группы из числа представителей государственных органов, органов местного самоуправления, общественных объединений, научных и других организаций, ученых и специалистов;

в) приглашать на свои заседания представителей государственных органов, органов местного самоуправления, общественных объединений, научных и других организаций;

г) привлекать в установленном порядке для осуществления информационно-аналитических и экспертных работ организации, а также ученых и специалистов, в том числе на договорной основе;

д) пользоваться в установленном порядке банками данных Аппарата

Президента Республики Татарстан и государственных органов Республики Татарстан.

6. Совет формируется в составе председателя Совета, его заместителя, ответственного секретаря и членов Совета, которые принимают участие в его работе на общественных началах.

7. Председатель Совета:

а) определяет основные направления деятельности Совета;

б) определяет дату, время, место проведения и повестку дня заседания Совета;

в) созывает и ведет заседания Совета, поручает при необходимости ведение заседаний Совета своему заместителю;

г) контролирует исполнение решений Совета по вопросам, относящимся к его компетенции;

д) утверждает составы постоянных и временных рабочих и экспертных групп.

8. Заседания Совета проводятся по мере необходимости, но не реже одного раза в квартал.

9. Информирование членов Совета о созыве заседания Совета осуществляется любым способом, обеспечивающим получение информации о дате, времени, месте проведения и повестке дня заседания Совета не позднее чем за три дня до дня заседания Совета.

10. Заседание Совета считается правомочным, если на нем присутствует не менее половины его членов. Решения Совета принимаются открытым голосованием простым большинством голосов его членов, присутствующих на заседании. При равенстве голосов голос председателя Совета (заместителя председателя Совета, проводящего заседание) является решающим. Решения Совета в течение трех дней после дня заседания Совета оформляются протоколом, который подписывает председатель Совета либо заместитель председателя, проводивший заседание Совета. Протокол в течение семи дней после дня его подписания рассылается членам Совета и при необходимости направляется в заинтересованные государственные органы, органы местного самоуправления и организации.

11. В составе Совета в целях рассмотрения вопросов, указанных в подпунктах «е» и «ж» пункта 4 настоящего Положения, формируется Комиссия по кадрам Совета (далее – Кадровая комиссия).

Кадровая комиссия формируется в составе председателя Совета, его заместителя, ответственного секретаря и иных членов Совета, определяемых решением Совета.

Регламент работы Кадровой комиссии определяется решением Совета.

12. Обеспечение деятельности Совета осуществляется Департаментом государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан и Управлением делами Президента Республики Татарстан.

___________

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан

от « 12 » июня 2014 года

№ УП-569

**Состав**
**Совета по вопросам кадровой политики**
**при Президенте Республики Татарстан**

| | |
|---|---|
| Сафаров Асгат Ахметович | Руководитель Аппарата Президента Республики Татарстан, председатель Совета |
| Гафаров Шамиль Хамитович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – Руководитель Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан, заместитель председателя Совета |
| Белов Александр Николаевич | руководитель Департамента государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан, ответственный секретарь Совета |
| Ажимова Ольга Александровна | директор общества с ограниченной ответственностью «Алтын юл», эксперт Высшей школы государственного и муниципального управления Казанского (Приволжского) федерального университета (по согласованию) |
| Бадрутдинов Марс Сарымович | начальник Управления Президента Республики Татарстан по вопросам антикоррупционной политики |
| Волкова Фарида Рахимовна | начальник Государственно-правового управления Президента Республики Татарстан |
| Гарипов Ильнур Махмутович | заместитель Руководителя Аппарата Президента Республики Татарстан – начальник Управления по работе с территориями Президента Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Гафуров<br>Ильшат Рафкатович | ректор Казанского (Приволжского) федерального университета (по согласованию) |
| Маврина<br>Лилия Николаевна | Секретарь Государственного Совета Республики Татарстан (по согласованию) |
| Маштакова<br>Галина Юрьевна | директор общества с ограниченной ответственностью «Джи Эм Си Консалтинг» (по согласованию) |
| Фаттахов<br>Энгель Навапович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр образования и науки Республики Татарстан |
| Фомин<br>Анатолий Алексеевич | председатель Общественной палаты Республики Татарстан (по согласованию) |
| Хамматова<br>Ангелина Анатольевна | судья Конституционного суда Республики Татарстан (по согласованию) |
| Шакиров<br>Минсагит Закирович | председатель Совета муниципальных образований Республики Татарстан (по согласованию) |

___________

Приложение № 3
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «12» июня 2014 года

№ УП-569

**Перечень**
**указов Президента Республики Татарстан, утративших силу**

1. Указ Президента Республики Татарстан от 21 ноября 2008 года № УП-596 «О Комиссии по формированию и подготовке резерва управленческих кадров в Республике Татарстан».
2. Указ Президента Республики Татарстан от 11 октября 2010 года № УП-680 «О Комиссии по вопросам развития государственной гражданской службы Республики Татарстан и муниципальной службы в Республике Татарстан».
3. Указ Президента Республики Татарстан от 14 февраля 2011 года № УП-58 «О внесении изменений в состав Комиссии по вопросам развития государственной гражданской службы Республики Татарстан и муниципальной службы в Республике Татарстан».
4. Указ Президента Республики Татарстан от 26 апреля 2011 года № УП-241 «О внесении изменений в состав Комиссии по формированию и подготовке резерва управленческих кадров в Республике Татарстан».
5. Пункты 1 и 2 Указа Президента Республики Татарстан от 24 июля 2012 года № УП-617 «О внесении изменений в отдельные акты Президента Республики Татарстан».
6. Пункт 8 Указа Президента Республики Татарстан от 7 марта 2013 года № УП-208 «О внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан».
7. Указ Президента Республики Татарстан от 18 октября 2013 года № УП-1029 «О внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан».
8. Пункт 5 Указа Президента Республики Татарстан от 11 декабря 2013 года № УП-1211 «О внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан».

___________

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы турында**

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне реформалау һәм үстерү эшен камилләштерү максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 42 статьясының 3 өлеше нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасының идарәче кадрлары резервын булдыру һәм аны нәтиҗәле файдалану максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советын оештырырга.

2. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Түбәндәгеләрне бетерергә:
Татарстан Республикасында идарәче кадрлар резервын формалаштыру һәм әзерләү комиссиясен;
Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү мәсьәләләре комиссиясен;

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүгә, аларның квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын үткәрүгә дәүләт заказы турында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-599 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 20 мартындагы ПУ-240 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәреше белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
а) 3 пунктның беренче абзацында һәм 4 пунктның икенче абзацында тиешле килештәге «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты» сүзләрен тиешле килештәге «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;
б) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүгә, аларның квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын үткәрүгә дәүләт заказы турында Нигезләмәдә:

5 пунктта, 6 пунктның беренче һәм икенче абзацларында, 9 пунктның беренче һәм икенче абзацларында, 12 пунктта, 13 пунктның беренче абзацында, 15 һәм 16 пунктларда тиешле килештәге «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты» сүзләрен тиешле килештәге «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү комиссиясенең» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы» сүзләренә алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервын формалаштыру тәртибе турында» 2009 елның 25 февралендәге 97 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 4 пунктта һәм 5 пунктның икенче абзацында тиешле килештәге «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты» сүзләрен тиешле килештәге «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервын формалаштыру тәртибе турында нигезләмәгә:

3 пунктта «Татарстан Республикасында идарәче кадрлар резервын формалаштыру һәм әзерләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан формалаштырыла» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы (алга таба – Совет) тарафыннан формалаштырыла» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның өченче абзацында, 13-23, 26 пунктларында һәм Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервына кертүне дәгъвалаучы анкетасына 2 номерлы кушымтада тиешле килештәге «Комиссия» сүзен тиешле килештәге «Совет» сүзенә алмаштырырга;

11 пунктның беренче абзацында, 12 пунктның беренче абзацында, 14, 22, 23 һәм 25 пунктларында тиешле килештәге «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты» сүзләрен тиешле килештәге «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга.

6. Татарстан Республикасы Президенты указларын 3 номерлы кушымта нигезендә үз көчләрен югалткан дип танырга.

7. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2014 ел, 12 июнь
№ ПУ-569

Татарстан Республикасы
Президентының
2014 елның «12» июнендәге
ПУ-569 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы турында**
**нигезләмә**

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы (алга таба – Совет) Татарстан Республикасы кадрлар потенциалын нәтиҗәле файдалану, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт системасын (алга таба – дәүләт һәм муниципаль хезмәт) үстерүгә ярдәм итү, шулай ук Татарстан Республикасында бердәй кадрлар сәясәтен куллану максатларында оештырыла.

2. Совет Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эшчәнлек алып бара.

3. Совет турында нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

4. Советның төп функцияләре түбәндәгеләр:

а) Татарстан Республикасы Президентына Татарстан Республикасы кадрлар сәясәтен, дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәтне оештыру һәм узуны, Татарстан Республикасында кадрлар белән идарә итү системасын камилләштерү турында тәкъдимнәр әзерләү;

б) Татарстан Республикасы Президентына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт турындагы законнарын камилләштерү турында тәкъдимнәр әзерләү;

в) Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервын формалаштыруны һәм аны нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү;

г) дәүләт хезмәтен һәм муниципаль хезмәтне үстерү буенча республика программаларын үтәүгә мониторинг;

д) Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри әзерлеген оештыру нәтиҗәлелеген анализлау;

е) аларга билгеләү һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Президенты яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

тарафыннан башкарыла торган вазыйфаларны биләү турында тәкъдимнәр әзерләү;

ж) Татарстан Республикасы Президентына, федераль законнарда, шартнамәләрдә һәм килешүләрдә каралган очракларда, үз вәкаләтләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимиятнең территориаль органнары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә күрсәтелгән кандидатураларны килештерү турында тәкъдимнәр әзерләү;

з) Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарында, шулай ук алар карамагындагы учреждениеләрдә кадрлар сәясәтен тормышка ашыруга мониторинг, Татарстан Республикасы Президентына бу өлкәдә эшләр торышы турында мәгълүмат бирү;

и) Татарстан Республикасы Президентына Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, дәүләт хезмәтенең иң югары вазыйфалар төркеменә керүче «җитәкчеләр» категориясе вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләренең һөнәри эшчәнлеген бәяләү буенча тәкъдимнәр бирү һәм оештыру чараларын уздыру;

к) дәүләт хезмәтен һәм муниципаль хезмәтне үстерүнең, персоналны үстерү һәм аның белән идарә итүнең аеруча актуаль проблемалары, дәүләт һәм муниципаль идарә өлкәсендә белгечләр әзерләү буенча илебездә һәм чит илләрдәге заманча алдынгы тәҗрибәне гомумиләштерү һәм тарату мәсьәләләре буенча республика күләмендә семинарлар, киңәшмәләр, конференцияләр уздыру турында тәкъдимнәр әзерләү;

л) Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсе буенча Совет компетенциясенә кергән башка мәсьәләләрне карап тикшерү.

5. Аңа йөкләнгән төп функцияләрне башкаруда Совет түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, җәмәгать оешмаларыннан, фәнни һәм башка оешмалардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле мәгълүматларны һәм материалларны соратырга һәм алырга;

б) Совет компетенцияләренә кергән мәсьәләләр буенча дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать оешмалары, фәнни һәм башка оешмалар вәкилләреннән, галимнәр һәм белгечләрдән торган даими яисә вакытлыча эшли торган эш һәм эксперт төркемнәре төзергә;

в) үз утырышларына дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать оешмалары, фәнни һәм башка оешмалар вәкилләрен чакырырга;

г) мәгълүмати-аналитик һәм эксперт эшләрен башкару өчен билгеләнгән тәртиптә оешмаларны, шулай ук галимнәрне һәм белгечләрне, шул исәптән шартнамәләр төзү юлы белән дә, җәлеп итәргә;

д) билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты Аппараты һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары мәгълүматлар банкларыннан файдаланырга.

6. Советның составы аның эшендә җәмәгать башлангычларында катнаша торган Совет рәисе, аның урынбасары, җаваплы секретарь һәм Совет әгъзаларыннан төзелә.

7. Совет рәисе:

а) Совет эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгели;

б) Совет утырышын уздыру көнен, вакытын, урынын һәм көн тәртибен билгели;

в) Совет утырышларын җыя һәм алып бара, кирәк булганда утырышлар уздыруны урынбасарына йөкли;

г) Советның үз компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча чыгарган карарлары үтәлешен контрольдә тота;

д) даими һәм вакытлыча эшли торган эш һәм эксперт төркемнәре составларын раслый.

8. Совет утырышлары ихтыяҗ туганда, әмма кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла.

9. Совет әгъзаларына Совет утырышын җыю турындагы мәгълүматны җиткерү, алар Совет утырышын уздыру көне, вакыты, урыны һәм көн тәртибе турындагы мәгълүматны Совет утырышына кимендә өч көн кала дигәндә алырлык итеп, теләсә нинди ысул белән башкарыла.

10. Совет утырышы, анда әгъзалары яртысыннан да ким булмаган санда катнашса, гамәлгә хокуклы дип санала. Совет карарлары аның утырышында катнашучы әгъзаларының ачык гади күпчелек тавыш бирүе нигезендә кабул ителә. Тавышлар тигез булса, Совет рәисе (утырышны алып баручы Совет рәисе урынбасары) тавышы хәлиткеч була. Совет карарлары Совет утырышы узганнан соң өч көн эчендә беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа Совет рәисе яисә аның Совет утырышын алып баручы урынбасары кул куя. Беркетмә аңа кул куелганнан соң җиде көн эчендә Совет әгъзаларына һәм, кирәк булганда, кызыксынган дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм оешмаларга җибәрелә.

11. Совет составында әлеге Нигезләмәнең 4 пунктының «е» һәм «ж» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау максатларында Советның кадрлар буенча комиссиясе (алга таба – Кадрлар комиссиясе) оештырыла.

Кадрлар комиссиясе составы Совет рәисе, аның урынбасары, җаваплы секретарь һәм Совет карары нигезендә билгеләнә торган аның башка әгъзалары кертеп формалаштырыла.

Кадрлар комиссиясенең эш регламенты Совет карары белән билгеләнә.

12. Совет эшчәнлеген тәэмин итүне Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты һәм Татарстан Республикасы Президентының Эшләр идарәсе башкара.

___________

Татарстан Республикасы
Президентының
2014 елның «12» июнендәге
ПУ-569 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы составы**

| | |
|---|---|
| Сәфәров<br>Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Совет рәисе |
| Гафаров<br>Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, Совет рәисе урынбасары |
| Белов<br>Александр Николаевич | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты җитәкчесе, Советның җаваплы секретаре |
| Ажимова<br>Ольга Александровна | «Алтын юл» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры, Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе эксперты (килешү буенча) |
| Бәдретдинов<br>Марс Сарыйм улы | Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы |
| Волкова<br>Фәридә Рәхим кызы | Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы |
| Гарипов<br>Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Гафуров<br>Илшат Рәфкать улы | Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры (килешү буенча) |
| Маврина<br>Лилия Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре (килешү буенча) |
| Маштакова<br>Галина Юрьевна | «Джи Эм Си Консалтинг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча) |
| Фәттахов<br>Энгель Нәвап улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Фомин<br>Анатолий Алексеевич | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Хамматова<br>Ангелина Анатольевна | Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы (килешү буенча) |
| Шакиров<br>Минсәгыйть Закир улы | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе (килешү буенча) |

________

Татарстан Республикасы
Президентының
2014 елның «12» июнендәге
ПУ-569 номерлы Указына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының үз көчләрен югалткан указлары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында идарәче кадрлар резервын формалаштыру һәм әзерләү комиссиясе турында» 2008 елның 21 ноябрендәге ПУ-596 номерлы Указы.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү мәсьәләләре комиссиясе турында» 2010 елның 11 октябрендәге ПУ-680 номерлы Указы.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү мәсьәләләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 14 февралендәге ПУ-58 номерлы Указы.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында идарәче кадрлар резервын формалаштыру һәм әзерләү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 26 апрелендәге ПУ-241 номерлы Указы.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 24 июлендәге ПУ-617 номерлы Указының 1 һәм 2 пунктлары.

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы Указының 8 пункты.

7. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 18 октябрендәге ПУ-1029 номерлы Указы.

8. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1211 номерлы Указының 5 пункты.

---